| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2020 г.Лениногорск № 36

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын раслау турында

«Туктар Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерүне тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураны үстерү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, ТР «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 25.05.202020-25.06.202020 елларда узган ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Туктар Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын расларга.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка житкерергә) һәм муниципаль районның рәсми сайтында «Интернет» челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http//Leninogorsk/tatarstan.ru урнаштырырга һәм «Лениногорские вести» газетында бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны "Архградстройконтроль" МБУ директоры О. В. Куприяновага йөкләргә.

Лениногорск муниципаль районы
башлыгы, Совет рәисе Р.Г. Хөсәенов